**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**

422750, село Большая Атня,
улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы,
Совет урамы,38нче йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«19» октября 2020 ел № 383

Татарстан Республикасы Әтнә районы башкарма Комитеты җитәкчесенең 2020 елның 21 августаындагы 286 номерлы карары белән расланган “Дини оешмаларга әлеге җир кишәрлегендә урнашкан биналар, корылмалар, дини һәм хәйрия билгеләнешендәге корылмалардан түләүсез файдалану срогына җир кишәрлеге бирүнең административ регламентына” үзгәрешләр кертү турында

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, "Инвалидлар хокуклары турында конвенцияне ратификацияләүгә бәйле рәвештә инвалидларны социаль яклау мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 01.12.2014 № 419 Федераль законына нигезләнеп, Әтнә район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әтнә районы башкарма Комитеты җитәкчесенең 2020 елның 21 августаындагы 286 номерлы карары белән расланган “Дини оешмаларга әлеге җир кишәрлегендә урнашкан биналар, корылмалар, дини һәм хәйрия билгеләнешендәге корылмалардан түләүсез файдалану срогына җир кишәрлеге бирүнең административ регламентына” түбәндәгу үзгәрешләр кертергә:

2 нче бүлекнең 2.14 пунктында 2 нче баганасын түбәндәге эчтәлекле кызыл юллар белән тулыландырырга:

"Инвалидларның дәүләт хезмәте күрсәтү урынына киртәләрсез үтеп керү мөмкинлеге, шул исәптән объектларга киртәләрсез керү һәм алардан чыгу, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү урынына керү максатларында объект буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге тәэмин ителә.

Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль текст һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла.";

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының (http://atnya.tatarstan.ru) рәсми сайтында шулай ук Татарстан Республикасы (https://pravo.tatarstan.ru/) хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе Р.Г. Мөхәмәтҗановка йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын үтәүче М.Л. Халиков